ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СТАРОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

КАРАР

2021 елның 27 сентябре

№ 19

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Иске Иштирәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 25 июлендәге 2 номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Иске Иштирәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу” муниципаль хезмәт күрсәтү регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы "Иске Иштирәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 10 июнендәге 6 номерлы номерлы карарының преамбула өлешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Иске Иштирәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 25 июлендәге 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы " Иске Иштирәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яисә килүче гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу” муниципаль хезмәт күрсәтү регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре»;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Иштирәк авылы, Мәктәп урамы, 15, Ялтау авылы, Тынычлык урамы, 27, Бәкер авылы, Нагорная урамы, 38 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
“Иске Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы

А.А.Вәлиәхмәтов